

# Төбәк телләре яисә азчылык телләренең Европа Хартиясе

## Төбәк телләре һәм азчылык телләренә тавыш бирү хокукын бирергә

Рамачная праграма супрацоўніцтва для Арменіі, Азербайджана, Грузіі, Рэспублікі Малдова, Украіны і Беларусі

Programmatic Cooperation Framework for Armenia, Azerbaijan, Georgia, Republic of Moldova, Ukraine and Belarus

Funded by the European Union and the Council of Europe

EUROPEAN UNION

COUNCIL OF EUROPE

CONSEIL DE L'EUROPE

Implemented by the Council of Europe

# Хартия: Төбәк телләре һәм азчылык телләренә тавыш биру хокукын биру




## Телне куллану аны көчле итә. Югалтмас өчен телне кулланыгыз!

Күпчелек Европа дәүләте территорияләрендә, күпчелекнең теленнән аерылып торган телдә сөйләшүче аерымланган кешеләр төркемнәре бар. Андый төбәк тел яисә азчылык тел ияләре саны киң чикләр арасында үзгәрә, шулай ук аларның аерым дәүләтләрдә булган хокук торышы кебек. Ләкин аларны барысын да үзләренең киләчәгенә карата югары яки түбән дәрәҗәдәге билгесезлек берләштерә.

Төбәк телләре яисә азчылык телләренең Европа Хартиясе — дөньядагы бердәнбер килешү, ул традицион төбәк телләре яисә азчылык телләренең саклануын һәм үсешен тәэмин итә.

Телнең сүнү барышын туктатырга була һәм хәтта кирегә борырга була, бу хакта төрле ил мисаллары дәлилли, аларның гаиләләрендә һәм төбәкләрендә традицион рәвештә сөйләшкән телне яшь буын өйрәнә һәм куллана.

Ләкин һәрбер Европа теле белән дә эш бу рәвештә бармый. Бер рәт тел ияләре саны өзлексез кими. Бу тенденцияне кирегә бормасак, ул һичшиксез моңа кадәр гасырлар буена традицион рәвештә кулланылган һәм төбәкнең аерылгысыз өлеше булган телләрнең үлүенә китерер.

## Төбәк телләре яки азчылык телләре

Хартия күпчелек халык сөйләшкән тел/телләргә кагылмый, хәтта тел ияләре саны аз булса да. Мигрантлар теле яки дәүләт теле диалектлары төбәк теле яисә азчылык телләре дип саналмый.

## Телне көндәлек тормышта куллану

Хартиядә көндәлек тормышта төбәк телләр яисә азчылык телләрне саклау һәм үсеш өчен ярдәм күрсәтү буенча төгәл кулланма бар. Дәүләтләрдән бу телләрдә белем алуны тәэмин итү, хезмәтләр күрсәтү, шулай ук пресса, радио, телевидение һәм яңа массакүләм мәгълүмат чаралары, һәм шулай ук административ хезмәтләрне тәэмин итү сорала.

Хартия төбәк телләрне һәм азчылык телләрне көндәлек тормыштагы бөтен юнәлешләрдә куллануга ярдәм итә, урам билгеләреннән алып, сәламәтлекне саклау һәм дәүләт хакимияте органнары белән бәйләнешкә кадәр.

## Тел куллануга төп роль бирелә

Төбәк телләр яисә азчылык телләре ияләре үз телләренә ярдәм күрсәтәләр, аларны иҗтимагый һәм шәхси тормышның төрле өлкәләрендә куллану юлы белән. Бары тик көндәлек актив кулланылуы аркасында гына тел яши һәм үсеш ала ала.

## Җәмәгать тәртибен һәм үзара килүшене тәэмин итүгә кертем

Төбәк телләргә яки азчылык телләренә хөрмәт һәм аларны куллануга булышлык тиешле илләрдәге рәсми телләр белән һәм аларны өйрәнү кирәклеге белән каршылыкка керми. Киресенчә: төбәк телләрне яки азчылык телләрен тану һәм алар ияләрен хөрмәтләү һәм мәдәният телләре белән бәйле булу җәмгыятьтә үзара аңлашу дәрәҗәсен арттырырга булыша.

Телләрне һәм телләр мәдәниятын хөрмәт итү берләштерү чарасы булып тора, ил бүлешү чарасы булып түгел. Бу төрле тел һәм мәдәнияте булган кешеләрне берләштерүнең иң яхшы, ә еш кына бердәнбер ысулы.

## Европа дәүләтләре өчен гомуми структура

Хартия азчылык телләрен саклауга юнәлтелгән һәм мәҗбүри көчкә ия булган бердәнбер халыкара документ. Документ катнашучы илләргә тел сәясәтен эшләп чыгару өчен халыкара дәрәҗәсендә танылган гомуми структураны бирә.

Хартия һәм милли азчылыкны саклау турындагы Кысалы килешү Европа Шурасының милли азчылыкны саклауны тәэмин итүгә озак вакытлы омтылышын күрсәтә.



## Дәүләтләр һәм НПО арасында хезмәттәшлек өчен платформа.

Тел саклау өлкәсендәге сәясәт тиешле тел ияләре белән хезмәттәшлек кысаларында гына булдырыла ала. Андый үзара хезмәттәшлек бөтен якларга файдалы. Хартиянең уңышлы тормышка ашырылуы хакимият һәм гражданлык җәмгыятенең тар әңгәмә алып бару мөмкинлегеннән тора.

## Мөһим адым — мониторинг

Дәүләтләр белән Хартия кагыйдәләрен үтәү процессына регуляр мониторинг үткәрү, килешүнең үсеше булган эффектив документ булуын гарантияли. Инде башлангыч этапларында мониторинг барышының нәтиҗәләре булып хакимиятнең үз тел сәясәтенең потенциалы һәм кимчелек яклары турындагы хәбәрдарлыкның үсүен билгеләргә була. Мониторинг шулай ук хакимият һәм тиешле тел ияләре арасында файдалы элемтәләр булдырырга булыша. Моннан тыш, элемтәләр төрле тел төркемнәре арасында урнаштырыла.

## Хартия йогынтысы

Хартия тормышка ашырылуның башлангыч этапларында ук уңай үзгәрешләргә ирешеп булды. Тормышка ашырылу дәверендә бик күп өстәмә проблемалар хәл ителде. Хартия бөтен телләрне саклау һәм аларның үсешен арттыруда процесс йөрткече булып тора, ул Европаның лингвистик күптөрлелеген үстерергә мөмкинлек бирә.

# Хартия процессы

## Процесска өч төп партнер кертелгән:

- Европа Шурасы
- дәүләт
- НПО/тел ияләре вәкилләре




## Конструктив әңгәмә

Хартия Европа Шурасы белән булдырылган һәм өзлексез мониторинг объекты булган килешү.

Европа Шурасы булдырган күпчелек килешүләр белән кебек, мониторинг ике дәрәҗәле ысул кулланып эшләнә. Беренче дәрәҗәдә ил үзе килешүне тормышка ашыруы турында белдерә.
Икенче дәрәҗә Европа Шурасы Комитет министрлыгы белән сайланган бәйсез экспертлар Комитеты тарафыннан уздырылган мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнә.

Мониторинг процессына бөтен яклар катнаштырылган: Европа Шурасы, милли хакимият һәм НПО/тиешле телләр ияләре вәкилләре. Бу бөтен якларны өзлексез әңгәмә өчен мәйданчык белән тәэмин итә һәм тел ияләренә тормышка ашыру барышында төп рольне тәэмин итә.

## Дәүләт

Дәүләт, Хартиянең III-нче Өлеше (68 йөкләмәдән ким дигәндә 35) нигезендә сакланган телләргә карата төрле йөкләмәләр билгеләп Хартияне раслый һәм кулын куя.

Раслаганнан соң бер ел дәвамында дәүләт Хартиянең III-нче Өлеше нигезендә үткәрелгән сәясәте турында һәм дәүләт белән кабул ителгән III-нче Өлеш кагыйдәләрен үтәү максатыннан кулланган чаралары турында беренче отчет тәкъдим итә. Киләсе отчетлар өч ел саен бирелә. Гадәттә дәүләт отчетны төбәк телләре яисә азчылык телләре ияләре вәкилләре белән килешеп әзерли. Бу тәкъдим ителгән тәҗрибә, чөнки ул үзара аңлашканлык дәрәҗәсен күтәрә һәм күп очракларда проблемаларны хәл итергә булыша.

Дәүләт периодик отчетларны нәшер итәргә бурычлы. Ул шулай ук Хартия төенендә нәшер ителә.

Европа Шурасы Хартияне раслауга әзерләнүдә дәүләткә булышу өчен семинар һәм киңәшмәләр оештыра ала. Дәүләт үзе шулай ук отчетлар әзерләгән вакытта һәм аларны тарату барышында киңәшмәләр оештыра ала. Андый семинар һәм киңәшмәләр шулай ук Европа Шурасы министрлар Коммитеты белән кабул ителгән рекомендацияләр һәм экспертлар Комитетының эксперт отчеты турындагы мәгълүматны тарату кысаларында оештырыла алалар.

## НПО/тел ияләре вәкилләре

НПО һәм бүтән тиешле тел ияләре вәкилләре Европа Шурасына (Хартия Секретариаты аша) һәм дәүләткә Хартияне тормышка ашыруга кагылган сораулар турындагы мәгълүмат бирү өчен төрле вакытта чакырыла алалар. Алар шулай ук дәүләт белән бирелгән отчетларны әзерләүгә актив катнашырга чакырылалар.

Отчет бирелгәннән соң була торган мониторинг барышында НПО һәм тел ияләре вәкилләре белән консультацияләр үткәрелә. Эш барышында алар шулай ук килешүне тормышка ашыруга кагылучы туган сораулар турында Хартия Секритариятын актив белдереп тору өчен инициатива күрсәтергә мөмкин.

## Экспертлар Комитеты

Хартия кагыйдәләрен куллану регуляр мониторингы Экспертлар Комитеты белән үткәрелә. Комитет дәүләт белән бирелгән һәрбер отчетны тикшерә һәм Европа Шурасы мистрлар Комитеты өчен бәяләү отчетын тәкъдим итә.

Закон нигезендә дәүләттә эшчәнлек алып барган органнар һәм оешмалар дәүләт белән кабул ителгән йөкләмәләргә бәйләнеше булган сорауларга экспертлар Комитеты игътибарын җәлеп итә алалар.



Бәяләү отчетын әзерләгән вакытта Комитет вәкилләре шулай ук дәүләткә мөрәҗәгать итәләр, җаваплы идарәдән һәм тиешле тел ияләре вәкилләреннән өстәмә мәгълүмат алу өчен (танышу максатыннан сәфәр). Андый тәҗрибә килешүнең үсеш алган эффектив коралы булуын гарантияли.

## Министрлар Комитеты

Экспертлар Комитеты уздырган анализ нәтиҗәләре нигезендә, министрлар Комитеты (Европа Шурасы әгъзалары булган илләрнең чит ил эшләре министрларыннан торган) Хартияне раслаган дәүләтләргә киңәшләрен тәкъбир итәләр. Министрлар Комитеты киңәшләре килешүнең иң йогынтылы коралы булып торалар. Ачыкланды, дәүләтләр, аларның күбесенең сәясәтенә йогынты ясаган, киңәшләргә игътибар белән карыйлар.

## Үтә күренмәле тәҗрибә

Хартия кысаларындагы процесс үтә күренмәле. Дәүләт отчетлары (өч ел саен бирелә торганнар), экспертлар Комитеты бәяләү отчетлары һәм министрлар комитеты киңәшләре министрлар Шурасы төенендә рөхсәтле, һәм алар белән һәрбер кеше таныша ала.

# Хартия ике сүздә




## Хартия структурасы

**I өлеш**
Хартиянең беренче өлешендә аның куллану өлкәсе билгеләнгән.

**II өлеш**
Хартиянең икенче өлешендә «Хартия рухы» чагылган. Ул төбәк телләр яисә азчылык телләренең мәдәни байлык чагылышы сыйфатында танылуында гыйбарәт. II өлеш кагыйдәләре дәүләттә традицион рәвештә булган барлык телләргә кагыла.

**III өлеш**
Дәүләт һичшиксез III өлешнең кагыйдәләренә җентеклерәк кертелгән телләрне билгели. Һәр тел өчен дәүләт 68 кагыйдәнең 35 кагыйдәсен кулланырга бурычлы.

**IV өлеш**
Хартияне тормышка ашыру процессының төп өлеше булып Хартияне куллану мониторингы булып тора. Мониторинг һәм куллану турындагы бүтән сораулар IV өлештә билгеләнгән.

**V өлеш**
Хартиянең үз көченә керүе һәм кул кую һәм раслау белән бәйле сораулар Хартиянең V өлешендә билгеләнгән.

## II ӨЛЕШ

## БАРЛЫК ТЕЛЛӘРГӘ КАРАТА КУЛЛАНГАН ПРИНЦИПЛАР ҺӘМ МАКСАТЛАР

II өлеш кагыйдәләре илдә традицион рәвештә булган барлык төбәк телләргә һәм азчылык телләренә кагылалар, дәүләт бу телне тулырак өлеше нигезендә саклау өчен сайланган яки сайланмаган булуыннан бәйсез рәвештә.

**II өлеш нигезендә түбәндәге төп принциплар кулланыла:**

- Хартия нигезендә төбәк телләрне яисә азчылык телләрен **мәдәни байлык чагылышы** дип тану һәм **андый телләрнең үсеше өчен тәвәккәл гамәлләр куллану кирәклеге** ята. Күпчелек дәүләтләр Хартиягә моңарчы дәүләтнең мәдәни һәм лингвистик мирасы өлеше булып танылмаган телләрне саклау һәм аларның үсешен тәэмин итү өчен кул куйдылар.

- Хартия шулай ук дәүләтләргә һәрбер төбәк телнең яисә азчылык теленең **географик районын хөрмәт итергә** мәҗбүр итә. Андый принцип тәҗрибәдә куллана, мәсәлән, әгәр дәүләт административ чикләрен үзгәртергә планлаштырса һәм бу үзгәртү төбәк телләр яисә азчылык телләренең үсешенә киртә куйса.

- Хартиянең төп принцибы булып телнең бары тик шәхси сферада гына куллану белән чикләнергә тиеш түгеллеге тора. Телнең **иҗтимагый тормышта** куллануга стимул бирелергә тиеш. Бу принцип нигезендә дәүләт һәм җирле хакимият телнең яңа куллану өлкәләрен булдыралар, алар арасында белем бирү, административ идарә итү, хөкем системасы, массакүләм мәтьбугат чаралары һәм икътисад.

- **Белем алу** төрле тел үсешенең бөтен дәрәҗәдә иң мөһим факторы булып тора. Хартия дәүләтләрдән төбәк телләрне яисә азчылык телләрен укыту яки өйрәнү өчен тиешле формалар һәм чаралар тәкъдим итәргә таләп итә. Шулай итеп, күпчелек очракта телдә белем алу яки телне укыту аерым дисциплина сыйфатында таэмин итүне яхшырту тәэмин ителә, алар арасында Хартиянең җентеклерәк III өлеше кысаларында сакланмаган телләр дә бар.




Телнең үсеше һәм саклавына юнәлтелгән Хартия Рухы телләр үсеше өчен уңай һәм конструктив чишелешләр табарга чакырылган. Бу дәүләтнең барлык лингвистик төркемнәр арасында **үзара ризалык** тәэмин итүен таләп итә, алар күпчелек тел иияләре, төбәк тел яисә азчылык теле ияләре булса да. Хартия нигезендә телгә карата хөрмәт, аңлау һәм толерантлык яталар. Ләкин Хартия шулай ук дәүләттән нигезсез чикләүне, чыгармаларны яки тел куллануга өстенле мөнәсәбәтне тыярга таләп итә.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары** роле бүтәннәргә, аларның мәдәниятына һәм теленә хөрмәтнең  һәм үзара аңлауның үсеше өчен бик мөһим. Хартия массакүләм мәгълүмат чараларын бу максатка омтылышларын стимуллаштырырга мәҗбүр итә.

Күпчелек очракта тел бер дәүләттә төбәк тел яисә азчылык теле булып тора, шул ук вакытта башка дәүләтләрдә ул шулай ук куллана һәм хәтта өстенлеккә ия. Хартия дәүләтләргә **трансчикле алышуны** актив үстерергә мәҗбүр итә. Бу алышуның төрле төрләренә кагыла, алар арасында массакүләм мәгълүмат чараларының файдалана алырлык булуы, мәдәни контактлар яки тел өйрәнү өчен курс булдыру максатыннан хезмәттәшлек.

## III ӨЛЕШ

# ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШНЫҢ 7 СФЕРАСЫНДА 98 ЧАРА САЙЛАУ

Хартиянең III өлешендә 68 статья күрсәтелгән, аларда бу өлеш нигезендә сакланырга дип билгеләнгән телләргә ярдәм күрсәтү өчен 98 чара тасвирланган. Һәрбер телгә ким дигәндә 35 шарт һәм ким дигәндә иҗтимагый тормышның 6 сферасы кулланырга тиеш. Ләкин, Хартия рухын чагылдырып, күпчелек андый телләр өчен дәүләтләр кимендә таләп ителгәннән күберәк йөкләмәләр сайладылар. Тәҗрибәдә, мәсәлән, бу түбәндәгеләрне аңлата ала:

## Белем бирү

- Тел ияләре балаларын тулысынча алар телләрендә белем бирүне тәэмин иткән яки, ким дигәндә, мәктәпкәчә белеменнән университет белеменә кадәр тиешле дәрәҗәдә аерым дисциплина сыйфатында тел өйрәнү өчен, мәктәпкә бирә алалар.
- Дәүләт мондый белем бирүне, һәм шулай ук укытучыларның тиешле әзерлеген тәэмин итергә тиеш.

## Хөкем

- Тел ияләре хөкем барышында, телдән яки язма тәрҗемәче өчен өстәмә чыгымнарсыз, үз телләрен кулланырга мөмкин.
- Дәүләт тиешле телдәге документларның хөкемдә хакыкый булуын гарантияләргә мәҗбүр.

## Административ органнар белән үзара бәйләнеш

- Тел ияләре үз телләрендә формаларны тутыра алалар һәм хакимият органнары белән язылыш алып бара алалар, үз исемнәрен һәм географик атамаларны үз телләрендә куллана алалар, һәм аларның телләре знакларда һәм күрсәткечләрдә куллана.
- Дәүләт тиешле телдә эшләү өчен административ органнарның компетенциясен тәэмин итергә тиеш.

## Массакүләм мәгълүмат чаралары

- Тел ияләре үз телләрендә радио һәм телевидение каналларын куллана алар яки, дәүләт хезмәтләре яисә хосусый оешмалар белән тапшырыла торган программаларны үз телләрендә регуляр тыңлыйлар/карыйлар, шулай ук алар газеталар укыйлар һәм азчылык телендә аудиовизуаль әсәрләр белән куллануга мөмкинлеккә ия.



Дәүләт дәүләт тапшырулары кысаларында тиешле телдә тапшырулар алып барышын тәэмин итергә яки андый хезмәтләрне күрсәтүче хосусый оешмаларга ярдәм күрсәтергә бурычлы, һәм шулай ук башка массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле ысуллар белән булышырга, мәсәлән, интернет челтәрендә.

## Мәдәни чаралар

Тел ияләренең мәдәни чараларын, китапханә һәм аларның телләрендә бастырылган китаплар куллануга мөмкинлекләре бар; телдә терминология үсеше тәэмин ителә.

Дәүләт төрле мәдәни чараларына ярдәм күрсәтү ягыннан финанс ярдәм һәм хуплау тәэмин итергә тиеш, һәм тел ияләре мәдәни чараларын планлаштырыр өчен чакырылачакларына гарантия бирергә тиеш.

## Икътисади һәм иҗтимагый тормыш

Тел ияләре телне иҗтимагый ярдәм эзләү өчен куллана алалар; телне куллану икътисади тормышның бөтен сфераларында куллана.

Дәүләт эш урыннарында телне куллану чикләүләрен бетерергә бурычлы, әгәр алар практика сәбәпләре белән акланмасалар.

## Дәүләт арасындагы алмашулар

Тел ияләре дәүләт арасындагы телевидение һәм радио хезмәтләре белән, уртак мәдәният чаралары һәм башка мөмкинлекләр белән куллана алалар, бу телләр кулланган күрше илләре белән чикләрнең ачык булулары аркасында мөмкин.

Дәүләт дәүләт арасы чараларына ярдәм күрсәтергә йөкләмә ала, кирәк булган очракларда күрше илләре белән килешүләр төзеп.

# Хартия кешеләрнең көндәлек тормышын уңай якка үзгәртә

Күпчелек мөнәсәбәтләрдә
Хартия төбәк телләре яисә азчылык
телләренең көндәлек торышына тәэсир ясый.



# Тел иялəре мөһим роль уйнарга тиеш

Төбəк теллəре яисə азчылык теллəренең үсешен һəм аларны саклауны тəэмин итү процессы итеп Хартия холкын аңлау бик мөһим. Һичшиксез, бу процесста, Хартия белəн саклау тəэмин ителүче теллəрнең көндəлектə куллануы бик зур роль уйный. Телнең килəчəге аны көн саен шəхси һəм иҗтимагый тормышта куллануыннан тора. Ул белем алу мөнəсəбəтендə сайлауга, мəдəни чаралар һəм массакүлəм мəгълүмат чараларындагы көндəлек куллануга таяна. Ул төбəк теллəре яисə азчылык теллəренең мөмкин булган җирлəрлəрдə куллану өстенлеген күрсəтүгə бəйле – административ хезмəтлəр күрсəткəндə һəм хакимият органнары белəн бəйлəнештə. Көндəлектə куллanusыз бүтəн тырышлыклар мəгънəсез булачаклар.

Түбəндə Хартиянең кешелəрнең көндəлек тормышын уңай якка үзгəртүнең берничə мисалы күрсəтелгəн:

- Алар үз теллəрен өйрəнə алалар һəм мəктəптə ул телдə сөйлəшə алалар
- Алар үз теллəрендə рəсми формаларны тутыра алалар
- Урам знаклары һəм географик атамалар алар телендə тəкъдим ителə
- Алар үз теллəрендə радио тыңлыйлар, телетапшырулар карыйлар һəм газета укыйлар
- Алар үзлəренең мəдəниятлары чагылышын тапкан актив мəдəни тормышта яшилəр, - əдəбият, театр, концерт, фестивальлəр һəм видеоматериаллар – үз теллəрендə.



## Хартия төенендә сез табачаксыз:

- Төбәк телләре һәм азчылык телләре Европа хартиясенең тулы текстын һәм аңлатмасын
- Хартияне раслаган һәм кул куйган дәүләтләр исемлеген
- Хартия кагыйдәләре кулланган телләр исемлеген
- Дәүләтләрнең периодик отчетларын, Европа Шурасы министрлар Комитеты белән тәкъдим ителгән Экспертлар Комитетының бәяләү отчетларын һәм киңәшләрен
- Хартия буенча әдәбият һәм өстәмә ресурсларга сылтамалар
- Периодик отчетлар әзерләү буенча хакимият органнары инструкцияләре
- Яңалыклар һәм Хартия кагыйдәләрен куллану турындагы мәгълүматлар

**www.coe.int/minlang**

Материал төбәк телләр яисә азчылык телләре
Европа хартиясе Секретариаты белән Европа Шурасы
аралашу Дирекциясе белән бәйләнештә әзерләнгән.

Бу документ Европа Шурасы һәм Европа союзы
арасында бергә оештырган проектлар фондларын
кулланып әзерләнгән. Бу документта язылган фикерләр
Европа союзнын рәсми фикерен тасвирлау өчен
берничек тә кулланыла алмый.

© Фотографияләр: Европа Шурасы

Европа Шурасы төбәк телләре яисә азчылык телләре Европа хартиясе төбәк яисә милли азчылыкларның традицион телләрен саклауга һәм үсешен булдырырга юнәлтелгән дөньядагы бердәнбер килешү. Хартия бу телләрнең көндәлек тормышта ничек кулланырга тиешлеге турында төгәл күрсәтмәләр бирә.

Татар теле Беларусиядә традицион кулланыла торган телләрдән азчылык файдаланучы телләрнен берсе булып тора.

**Европа Шурасы төбәк телләре яисә азчылык телләре Европа хартиясе Секретариаты**

F-67075 Страсбург, Cedex
Телефон: (кабул итү) +33 (0)3 88 41 20 00
minlang@secretariat@coe.int

**www.coe.int/minlang**

TAT

Европа Шурасы кеше хокуклары буенча континенттагы әйдәп баручы оешма. Ул үз эченә 47 әгъза-дәүләтләр кертә, аларның 28 дәүләте Европа союзы әгъзалары. Барлык Европа Шурасының әгъза-дәүләтләре дә кеше хокуклары турындагы Европа Конвенциясенә кул куйдылар, бу килешү кеше хокукларын, демократияне һәм хокук өстенлеген саклауга юнәлтелгән. Кеше хокуклары буенча Европа хөкеме әгъза-дәүләтләрдә Конвенциянең үтәлүе артыннан күзәтә.

**www.coe.int**

Европа Союзы 28 демократик Европа илләре арасында икътисади һәм сәяси уникаль хезмәттәшлек. Аның максаты – аның 500 миллион гражданныры өчен дуслык, алга бару һәм азатык – гаделерәк, куркынычсызрак дөньяда. Моны булдырыр өчен, ЕС илләре ЕС идарә итү органнарын булдырдылар һәм үз канунчылыгын кабул иттеләр. Европа парламенты (Европа халыкларын тәкъдим итүче), Европа союзы Шурасы (милли хөкүмәтләр тәкъдим итүче) һәм Европа комиссиясе (ЕС гомуми кызыксынуларын тәкъдим итүче) төп идарә итү органнары булып торалар.

**http://europa.eu**

Рамачная праграма супрацоўніцтва для Арменіі, Азербайджана, Грузіі, Рэспублікі Малдова, Украіны і Беларусі

**Programmatic Cooperation Framework for Armenia, Azerbaijan, Georgia, Republic of Moldova, Ukraine and Belarus**

Funded by the European Union and the Council of Europe

EUROPEAN UNION

COUNCIL OF EUROPE

CONSEIL DE L'EUROPE

Implemented by the Council of Europe